СОВЕТ
БИЛЯРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БИЛӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.07.2022 с. Билярск № 29

**Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге советының 12.04.2016 №27 нче «Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр, шулай ук муниципаль берәмлектә муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында (16.11.2018ел №86, 25.06.2021ел №20 дәге үзгәрешләр белән.)**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 ел, № 90-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә,

**Биләр авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, 8 пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:
«3) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган

балаларының җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемennән артып китсә, алар хисабына алыш-биреш ясалган акча алу чыганаклары турында.» .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Г. Г. Хәбибуллин**